| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 11.11.2020 г. Казань № 223-30/тэ-2020

«Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2021-2023 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» МУП) тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә), әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Әлеге карарның 2 кушымтасы нигезендә 2021-2023 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып, тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрларын билгеләргә.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.11.2020 № 223-30/тэ-2020
номерлы карарына 1 нче кушымта

«Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2021-2023 елларга календарь буенча бүлгәләнгән тарифлар

<table>
<tr><th rowspan="2">№ т/с</th><th rowspan="2">Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре</th><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Су</th><th colspan="4">Басым астында сайланган пар</th><th rowspan="2">Әче һәм редукцияләнгән пар</th></tr>
<tr><th>1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр</th><th>2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$кадәр</th><th>7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$кадәр</th><th>13,0 кг/см$^2$ югары</th></tr>
<tr><td></td><td colspan="8">Питрәч муниципаль районы</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="8">«Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе</td></tr>
<tr><td>1.1</td><td colspan="8">Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта</td></tr>
<tr><td rowspan="6"></td><td rowspan="6">бер став-калы, сум/Гкал</td><td>01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр</td><td>1682,71</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр</td><td>1729,01</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр</td><td>1729,01</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр</td><td>1785,05</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр</td><td>1785,05</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр</td><td>1833,12</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.11.2020 № 223-30/тэ-2020
номерлы карарына 2 нче кушымта

## Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2021-2023 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| № т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларыннан җибәрелә торган җылылык энергиясе берәмлеген җитештерүгә чыгымның чагыштырма чыгымы | Җылылык энергиясенең технологик сарыфлары зурлыгының җылылык челтәренең матди сыйфатламасына карата нисбәте | Җылылык челтәрләре буенча җылылык энергиясен тапшырганда технологик югалту күләме |
| | | | мең сум | % | ш.я.кг/Гкал | Гкал/м² | Гкал/ел |
| Питрәч муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе | 2021 | 6955,88 | 1 | 129,78 | 1,66 | 1 347,6 |
| | | 2022 | Х | 1 | 129,78 | 1,66 | 1 347,6 |
| | | 2023 | Х | 1 | 129,78 | 1,66 | 1 347,6 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге